ГЛАВА ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.11.2015 с. Печищи № 1

« 2016 елга Югары Ослан районының Печищи авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан районының Печищи авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегендә яшәүчеләрнең 2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең бюджет проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын саклау максатыннан, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Печищи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 4 декабрендә 15.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3.Үткәрү урыны - Печищи авылы, Декабристлар ур., 35а йорт Печищи авыл җирлеге башкарма комитеты.

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр , ачык тыңлауларда катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирелә ала торган адрес - Печищи авылы, Декабристлар ур., 35а йорт, Печищи авыл җирлеге башлыгы А.С. Шәмсетдинов (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2015 елның 25 ноябренә кадәр (тел 2-29-44).

3. Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советының

"2016 елга Печищи авыл җирлеге бюджеты турында" карары проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге Карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.2. Гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан районының Печищи авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук Югары Ослан районының Печищи авыл җирлегенең 2016 елга эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны “Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге бюджеты турында”гы Печищи авыл җирлеге Советы карары проектын Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы А.С. Шамсутдинов